СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**17.12.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 445**

Зеленодольск муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Советының норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрдә шәхси ярдәмче хуҗалык, индивидуаль торак төзелеше, гараж төзелеше алып бару өчен гражданнарга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен раслау турында» 2006 елның 7 сентябрендәге 90 номерлы;
- «Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшнамәсен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 30 октябрендәге 486 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлары үзгәрешләренә мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 мартындагы 370 номерлы карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**